РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
Старосалмановского сельского поселения Алькеевского муниципального района

Әлки муниципаль районы
Иске Салман авыл җирлеге
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422894, РТ, Алькеевский район, с. Старые Салманы, Клубная, 1

Адресы: 422894, РТ, Әлки районы, Иске Салман авылы, Клуб ур., 1

тел: : 8 (84346) 79-8-49

факс: 8 (84346) 79-8-49

РЕШЕНИЕ Иске Салман авылы КАРАР

2025 елның " 25 " июне № 134

Иске Салман авыл җирлеге Советы 01.12.2021 елгы № 34 «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Иске Салман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмәне раслау хакында" карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 19 пункты, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Иске Салман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Салман авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. Иске Салман авыл җирлеге Советының 01.12.2021 елгы №34 (үзг.04.02.2022 ел № 44, 21.06.2022 ел №52, 13.12.2023 ел № 89, 26.06.2024 № 106, 24.12.2024 ел №121) карары белән расланган Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Салман авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

4.23 нче пунктның 1 нче подпункты яңа редакциядә бәян итәргә:

1) контроль (күзәтчелек) чарасы актын рәсмиләштергәннән соң контрольдә тотылучы затка мәҗбүри таләпләрне ачыкланган бозуларны бетерү турында, аларны бетерүнең акыллы срокларын, шулай ук Контроль төре турындагы Федераль законда каралган башка чараларны күрсәтеп, күрсәтмә бирергә.

3 нче кушымтаның 2 пунктындагы 6 нчы искәрмәне үз көчен югалткан дип таныра.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Әлки муниципаль

районының рәсми сайтында (https://alkeevskiy.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Иске Салман авыл җирлеге комитеты
Башкарма Комитет Җитәкчесе И.А.Ферапонтова